КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 20 ноябрь г.Казань № 1491

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен раслау турында» 2022 ел, 6 июнь, 522 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибенә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 18 август, 855 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның икенче абзацында татар текстында «, «2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләреннән соң «Концессия килешүләре турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган объектларга карата концессия килешүләре, «Россия Федерация-сендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган объектларга карата дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү, муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү» сүзләрен өстәргә;

12 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Гомумтаралган файдалы казылмалардан һәм җир асты суларыннан үз ихтыяҗлары өчен файдалану дигәндә җир кишәрлекләре милекчеләренең, җирдән файдаланучыларның, җир биләүчеләрнең, җир кишәрлекләрен арендага алучыларның алардан шәхси, көнкүреш һәм эшкуарлык эшчәнлеген башкаруга бәйле булмаган башка ихтыяҗлар өчен файдалануы аңлашыла.

Җир кишәрлегендә табылган һәм җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир биләүчеләр, җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан шәхси, көнкүреш һәм эшкуарлык эшчәнлеген башкаруга бәйле булмаган

башка ихтыяҗлар өчен файдаланыла торган гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары читләштерелми яисә бер заттан икенчесенә күчә алмый.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен яки берләштерелгән лицензия буенча аларны геологик өйрәнүне, разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен, эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итүгә яки техник су белән тәэмин итүгә файдаланыла торган җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү өчен, җир асты суларын разведкалау һәм чыгару өчен яки җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, аларны чыгару максатларында геологик өйрәнү өчен, коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен һәм (яки) коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләрен эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итүгә яки техник су белән тәэмин итүгә файдаланыла торган җир асты суларын чыгару өчен, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен файдалануга бирү тәртибе» 2022 ел, 15 июнь, 564 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 18 август, 855 нче; 2022 ел, 29 сентябрь, 1050 нче һәм 2023 ел, 23 гыйнвар, 35 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен яки берләштерелгән лицензия буенча аларны геологик өйрәнүне, разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен, эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итүгә яки техник су белән тәэмин итүгә файдаланыла торган җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү өчен, җир асты суларын разведкалау һәм чыгару өчен яки җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, аларны чыгару максатларында геологик өйрәнү өчен, коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен һәм (яки) коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләрен эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итүгә яки техник су белән тәэмин итүгә файдаланыла торган җир асты суларын чыгару өчен, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен файдалануга бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктның «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару, шул исәптән файдалы казылмаларны һәм җир асты байлыклары калдыкларыннан, шул исәптән каплаган һәм эчендә урнашкан тау токымнарыннан файдалы компонентлар чыгару, җир асты байлыкларыннан файдаланучылар җир асты байлыкларын, шул исәптән каплаган һәм эчендә урнашкан тау токымнарын файдалану, углеводород чималын разведкалаганда һәм чыгарганда тау токымнары катламнарында җир асты байлыкларыннан файдаланучылар иярчен суларны һәм үз җитештерү һәм технологик ихтыяҗлары өчен кулланылган суларны урнаштыру, тау токымнары катламнарында разведкалауны һәм чыгаруны, шулай ук калий һәм магний тозларын беренчел эшкәртүне гамәлгә ашыручы җир асты байлыкларыннан файдаланучыларда барлыкка килгән суларны урнаштыру;»;

2.1 пунктның «б» пунктчасындагы җиденче абзацында татар текстында

«2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләреннән соң «, «Концессия килешүләре турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган объектларга карата концессия килешүләре, «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган объектларга карата дәүләти-хосусый партнерлык турында килешүләр, муниципаль-хосусый партнерлык турында килешүләр» сүзләрен өстәргә;

4.1 пунктның «е» пунктчасында татар текстында «, «2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләреннән соң «Концессия килешүләре турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган объектларга карата концессия килешүләре, «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган объектларга карата дәүләти-хосусый партнерлык турында килешүләр, муниципаль-хосусый партнерлык турында килешүләр» сүзләрен өстәргә;

5.5 пунктта:

беренче абзацта татар текстында «, «2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләреннән соң «, «Концессия килешүләре турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган объектларга карата концессия килешүләре, «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган объектларга карата дәүләти-хосусый партнерлык турында килешүләр, муниципаль-хосусый партнерлык турында килешүләр,» сүзләрен өстәргә;

«д» пунктчаның беренче абзацында татар текстында «2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләреннән соң «, «Концессия килешүләре турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган объектларга карата концессия килешүләре, «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган объектларга карата дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү, муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин